СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**8 сентябрь, 2025 ел** **№ 549**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 1743 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан түбәндәге боерыклар раслау белән бәйле рәвештә:

- 2025 елның 16 маендагы 617/о номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында»;
- 2025 елның 19 маендагы 633/о номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Усад авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында», Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының түбәндәге карарларының үз көчен югалтуын танырга:

- 2023 елның 07 июнендәге 299 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында»;
- 2023 елның 21 ноябрендәге 341 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында»;
- 2023 елның 28 декабрендәге 379 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында».

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына Федераль дәүләт территориаль планлаштыру мәгълүмат системасының рәсми сайтында мәгълүматны актуальләштерүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль

районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар аны рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов